РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.02.2021 г. с. Сарманово № 24

Россия Федерациясе
бюджет системасы бюджетына түләүләр
буенча бурыч булу (булмау) турында
салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү
эшен оештыру турында

Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты үзара мәгълүмати хезмәттәшлек буенча Килешүне гамәлгә ашыру максатларында 22.01.2021 № 2.1-21/3 карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү эшен оештырырга.
2. Мәгариф бүлеге, Башкарма комитетның инфраструктураны үстерү бүлеге, Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы, Башкарма комитетның исәп һәм хисап бүлеге, Сарман МР Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге, Җәлил ш.т.п Башкарма комитетына, Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 07 августындагы 674 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә һәм дәүләт вазыйфаларын башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек Тәртибе нигезендә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруга заявканы 2021 елның 3 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең мәгълүматлаштыру һәм элемтә цифрлы үсеш министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары Г.А. Галимовага йөкләргә.

МР Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Г. А. Галимова